Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Өркеш авыл җирлеге Башкарма комитеты

# КАРАР

«9» февраль, 2026 ел №3

«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Өркеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган "Кукмара муниципаль районының Өркеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Өркеш авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1. 2026 елның 24 февралендә 17 сәгать 00 минутта Югары Арбаш авыл мәдәният йорты бинасында (ТР, Кукмара районы, Югары Арбаш авылы, Яшеллек урамы, 104 а) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Өркеш авыл җирлеге, Югары Арбаш ав., Яшеллек ур, 74 А адресында урнашкан кадастр номеры16:23:240502:374, 230 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Шәхси торак төзелеше зонасында «Кибетләр» (Ж1) – рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2. Халыкка гавами тыңлаулар уздыру башлануы турында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында httrs://kukmor.tatarstan.ru адресында урнаштыру юлы белән һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Өркеш авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлауларда катнашучыларның күрсәтелгән мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә торган махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының яисә җыелышларының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм шушы проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат;

4) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенең яисә экспозицияләренең урыны, ачылу датасы турында, мондый проект экспозициясен яки экспозицияләрен үткәрү вакыты турында, күрсәтелгән экспозицияне яки экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) гавами тыңлауларда катнашучыларның гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат;

- «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерык проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru урнаштырырга;

- 2026 елның 09 февраленнән 2026 елның 24 февраленә кадәр Өркеш авыл мәдәният йорты бинасында гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачарга һәм үткәрергә, адресы: ТР, Кукмара районы, Югары Арбаш ав., Яшеллек ур., 104 а. Экспозицияне эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш;

- гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;
- гавами тыңлауларга әзерлекне, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән вакытта уздыруны тәэмин итәргә;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар йомгаклары буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Ш.Әгъләмова